ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Олы Битаман авыл җирлеге буенча
Бикнарат авылында халык җыены нәтиҗәләре турында
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы

от 09 ноябрь 2020 г. №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 29 октябрендәге 10 сәгать 00 минутта «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Бикнарат авылында рәсми теркәлгән һәр балигь булган гражданнан 500 сум күләмендә акча җыярга һәм җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә ризамы:

а) урам яктырткычлары кую;

б) щебень сатып алу;

в) Бикнарат авылы эченәге юлларны төзекләндерү.

«Әйе» «Юк» мәсьәләсе буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 118 (йөз унсигез) катнашучы, тавыш бирүдә 63 (алтмыш өч) кеше катнашкан гражданнар саны кертелгән, бу 53% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде:

җыенда катнашучыларның 63 (алтмыш өч) «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде; 0 катнашучы «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлегенең Бикнарат авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре – чын.

2. 2021 елда үзара салым акчасын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Битаман авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган гражданнан 500 сум (биш йөз) күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) урам яктырткычлары кую;

б) щебень сатып алу;

в) Бикнарат авыл эчендәге юлларны төзәекләндерү.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://pravo.tatarstan.ru/

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче А.Ә.Әминов